ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.7, пос. Октябрьский,
422580

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печище авылы,
422592

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

16.11.2019 — 165

Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский  авыл җирлегенең
Яңа Болгар авылы гражданнарның үзара салым акчаларын җыю
Тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Уставы нигезендә, 2019 елның 16 ноябрендәге гражданнар җыенында кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру максатларында, Октябрьский авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирде:

1. Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Яңа Болгар авылында үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземә калдырам.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы — Ш.Р. Азизов

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Октябрьский авыл җирлеге
Башкарма комитетының 2019 елның
16 ноябрендәге165 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының
Октябрьский авыл җирлегенең Яңа-Болгар авылында гражданнардан
үзара салым җыю тәртибе

1. Әлеге Тәртип Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегенең Яңа Болгар авылындагы үзара салым акчасын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчасын түләү гражданнар җыенында катнашуларына бәйсез рәвештә, Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар һәм алар тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйле рәвештә 2020 елның 1 гыйнварыннан 2020 елның 31 мартына кадәр гамәлгә ашырыла.

3. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы имза яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән гражданнарга җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (хәбәр итү) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

4. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә.

5. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия булган оешмалар (исәп-хисап оешмалары) аша почта күчерүе аша яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша башкарыла( https://uslugi.tatarstan.ru/).

6. Керем касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслый.

7. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.